**СОВРЕМЕННЫЙ МУСУЛЬМАНСКИЙ МИР**
МЕЖДУНАРОДНЫЙ НАУЧНЫЙ ЖУРНАЛ РОССИЙСКОГО ИСЛАМСКОГО ИНСТИТУТА
www.islamjournal.ru

Юсупова Н. М. Урта гасыр төрки-татар шигъриятендә суфичылык традицияләре [Электронный ресурс] / Н. М. Юсупова, А. Ф. Юсупов // Современный мусульманский мир : электрон. журнал. – 2018. – № 1. – 1 электрон. опт. диск (CD-ROM). Систем. требования: Pentium III, процессор с тактовой частотой 800 Мгц; 128 Мб; 10 Мб; Windows XP/Vista/7/8/10; Acrobat 6 х.

**Современный мусульманский мир. 2018. №1. ID 29**
**ISSN: 2587-6848**
**Свидетельство о регистрации СМИ: ЭЛ № ФС 77 - 69532 от 25.04.2017**

**Юсупова Нурфия Марсовна**
*Филология фәннәре кандидаты, доцент, КФУның Лев Толстой исемендәге филология һәм мәдәниятара багланышлар институты татар әдәбияты кафедрасы доценты, Казан*
*faikovich@mail.ru*

**Юсупов Айрат Фаикович**
*Филология фәннәре кандидаты, доцент, КФУның Лев Толстой исемендәге филология һәм мәдәниятара багланышлар институты татар тел белеме кафедрасы доценты, Казан*
*faikovich@mail.ru*

УДК 821.512.145,82:801.6

# УРТА ГАСЫР ТӨРКИ-ТАТАР ШИГЪРИЯТЕНДӘ СУФИЧЫЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

*Әлеге мәкаләдәурта гасырлар төрки-татар шигърияте мисалында суфичылык традицияләренең дәвам ителешенә күзәтү ясала, үсеш-үзгәреш үзенчәлегебилгеләнә.Суфи шигъри әсәрләр нигезендәсуфичыл дөнья сурәтенең үзенчәлекләре билгеләнә, суфи символларның мәгънәви бөтенлеге, функциясе, алар аша чагылганфәлсәфи мотивлар билгеләнеп бара. Татар суфи поэтик мирасы суфичыл дөнья моделенең бирелеше һәм суфи фәлсәфә чикләрендә бәяләнеп бара.*

*Ачкыч сүзләр:суфичылык,традиция,символ,дөнья сурәте,төрки-татар шигърияте.*

# СУФИЙСКИЕ ТРАДИЦИИ В СРЕДНЕВЕКОВОЙ ТЮРКО-ТАТАРСКОЙ ПОЭЗИИ

*В данной статье раскрываются суфийские традиции в тюрко-татарской поэзии Средневековья, выявляются основные тенденции развития. На материале суфийских поэтических произведений выделяются часто*

**СОВРЕМЕННЫЙ МУСУЛЬМАНСКИЙ МИР**
МЕЖДУНАРОДНЫЙ НАУЧНЫЙ ЖУРНАЛ РОССИЙСКОГО ИСЛАМСКОГО ИНСТИТУТА
www.islamjournal.ru

Юсупова Н. М. Урта гасыр төрки-татар шигъриятендә суфичылык традицияләре [Электронный ресурс] / Н. М. Юсупова, А. Ф. Юсупов // Современный мусульманский мир : электрон. журнал. – 2018. – № 1. – 1 электрон. опт. диск (CD-ROM). Систем. требования: Pentium III, процессор с тактовой частотой 800 Мгц; 128 Мб; 10 Мб; Windows XP/Vista/7/8/10; Acrobat 6 x.

**Современный мусульманский мир. 2018. №1. ID 29**
**ISSN: 2587-6848**
**Свидетельство о регистрации СМИ: ЭЛ № ФС 77 - 69532 от 25.04.2017**

*используемые бинарные оппозиции в религиозной картине мира, определяются смысловая и философско-эстетическая нагрузка суфийских символов, их функции, роль и художественное значение. Тюрко-татарская поэзия данного периода исследуется на фоне воссоздания религиозной картины мира, а также в широком контексте восточной литературы и исламской философии.*

*Ключевые слова*: *суфизм, традиция, символ, картина мира, тюрко-татарская поэзия.*

Татар шигърияте тарихында урта гасыр дәвередөнья сурәтенең үзенчәлеге белән дә, дөньяны фәлсәфи күзаллау ягыннан, сәнгати үзенчәлекләр җәһәтеннән дә үзенчәлекле чорларның берсен тәшкил итә. Билгеле булганча, XIX гасырның икенче яртысына кадәрге сүз сәнгате үсешендә болгар чорыннан башланган урта гасырлар баскычы дәвам итә [1: 206]. Дөнья әдәбияты үсеше чылбырында архаик чорга, мифопоэтик аң чагылышына алмашка килгән бу этап традицион иҗади аң (канунчылык) хакимлек иткән вакыт буларак мәгълүм.

Билгеләнгәндәвер татар шигъриятендәдини-дидактик, яңарыш, суфичылык өч мөстәкыйль әдәби юнәлешне хасил итә һәм параллель төстә үсә-үзгәрә. Көнчыгыш әдәбиятында киң таралыш алган суфичылык, ул тәкъдим иткән концепцияләр, аерым бер өйрәтүләр шәрык дөньясы, гарәп, фарсы һәм төрек әдәбиятлары белән тыгыз бәйләнешләрдә яшәгән, бер яссылыкта үскән татар әдәбияты тарихында да тирән чагылыш таба.

Дини-суфичыл үзенчәлекләрурта гасырлардан алып, XIX гасырның беренче яртысына кадәргетатар поэзиясендә дә чагылыш таба. Дини дөнья сурәтендә бердәнбер оппозиция: тормыш (кеше) / Алла алгы планга чыга[7:230]. Шушы оппозициянең төрле модификацияләре – шәхси / илаһи; җир тормышы / күк тормышы; ялган / хакыйкать; вакытлы / мәңгелек; ямьсезлек / матурлык; яхшылык / явызлык – ахыр чиктә бер фикергә алып килә: бердәнбер матурлык, яхшылык, хакыйкать Алла икәнлекне искәртә [8: 209].

Кеше / Алла оппозициясе, әлбәттә, ислам диненең төп кануннарына һәм Коръәнгә барып тоташа. Бөтен җан ияләрен, тереклекне, яшәешне Алла яраткан дигән фикер мөселманнарның дөньяга карашында аксиома булып тора. Шушы илаһи гамәлнең сәбәпләрен барлап, фәлсәфә чикләрендә нур (эманация) концепциясе пәйда була. Т. Ибраһим Әл-Фәраби трактатларында беренче тапкыр дөнья яратылышының нур агышы кебек шәрехләнүен билгели [2: 31].

СОВРЕМЕННЫЙ МУСУЛЬМАНСКИЙ МИР
МЕЖДУНАРОДНЫЙ НАУЧНЫЙ ЖУРНАЛ РОССИЙСКОГО ИСЛАМСКОГО ИНСТИТУТА
www.islamjournal.ru

Юсупова Н. М. Урта гасыр төрки-татар шигъриятендә суфичылык традицияләре [Электронный ресурс] / Н. М. Юсупова, А. Ф. Юсупов // Современный мусульманский мир : электрон. журнал. – 2018. – № 1. – 1 электрон. опт. диск (CD-ROM). Систем. требования: Pentium III, процессор с тактовой частотой 800 Мгц; 128 Мб; 10 Мб; Windows XP/Vista/7/8/10; Acrobat 6 х.

**Современный мусульманский мир. 2018. №1. ID 29**
**ISSN: 2587-6848**
**Свидетельство о регистрации СМИ: ЭЛ № ФС 77 - 69532 от 25.04.2017**

Лəкин эманация концепциясен гамəлгə куючылар - суфилар –суфичылыкның ишра-кийа агымы тарафдарлары була. Шаһабеддин ас-Сөхраварди (1155–1191) хезмəтлəрендə эманация –Алладан нур аерылып чыгып, мөстəкыйль субстанция –тормышны барлыкка китерүе аңлатыла, Мөхəммəт əл-Газали эманацияне кояш нурына тиңли. Процессны аңлату өчен тормыш –Алланың чагылышын бирүче көзге дигəн формула тəкъдим ителə [3:17–19]. Шуңа күрə дə дөнья сурəтендəге телəсə нинди оппозициянең бер ягында Алла торуы шарт ителə. Тормыш, кеше һəрвакыт Алланың күлəгəсе кебек шəрехлəнə [6: 16].

Нур фəлсəфəсендə тормыш Алла сурəтен чагылдырырлык көзгегə əйлəнсен өчен, Адəмнең дөньяга китерелүе күрсəтелə һəмулАлла сурəтен кабатлаучы буларак билгелəнə. Адəм һəм пəйгамбəрлəр үзлəренең сыйфатлары белəн Аллага, камиллеккə якынаялар һəм улшигъри əсəрдə Алла / кеше янəшəлегендə урын ала. Әлеге модификация суфи мəдəниятте иң актуальлəрдəн санала.

Суфичылык фəлсəфəсе ике – Ибн Гарəби исеме белəн бəйле вəхдəт-и вөҗүд (һəрнəрсə – Аллаh) һəм Раббани шəхесе белəн бəйле вəхдəт-и шəүхүд (һəрнəрсə – Аллаhтан) юнəлешлəренə аерылып [5: 96], татар суфичылык поэзиясендə соңгысы чагылыш таба, һəрнəрсəне бар иткəн Аллаhка интуитив, йөрəк аша якынаеп, хакыйкатьне табу мөмкинлеге хакында сүз алып барыла.

Суфичылыкта Аллаh юлына чыккан кешенең кəефе “хəл”дип атала һəм аның тугыз төре əйлəнешкə керə: Илаhка якынлыкны сизү, Илаhи гыйшык, гөнаhлы булуны төшенү, Аллаhның кичерəчəгенə өмет итү, хис ташкыны, дуслык-якынлык, рухи тынычлык, Аллаhны күрүгəирешү, Аның барлыгына һəм берлегенə ышану. Әлеге халəтлəр татар суфичылык шигъриятендə дə лирик герой кичерешлəре аша тергезелə. Мистик танып-белүнең төп баскычлары буларак шəригать, тарикать, хакыйкать аерып куела.

Суфичылык сүз сəнгате мистик характерлы, серлелекне, дөньяны танып бетерə алмау фикерен алга сөрə, аңа фикерне «ачкыч» булган символлар, киная, төслəр символикасы аша җиткерү хас. Суфилар əдəбият мəйданын үз фикерлəрен халыкка җиткерү, Хакыйкатьне ирештерү максатыннан отышлы файдалана. Суфичылык əдəбияты, нигездə, шигърият белəн билгелəнə, үзе дə серлелеккə омтылган поэзия суфи авторлар өчен дөньяви һəм яшерен, трансценденталь идеялəрне, фикерлəрне, сакраль эчтəлекне җиткерүдə чиклəнмəгəн мөмкинлеклəр ача [4: 31].

Суфичылык традициялəренең чагылышын, дөнья моделенең чагылышын аерым əсəрлəр мисалында төгəллəштерик. Мəсəлəн, XVI гасырның күренекле

**СОВРЕМЕННЫЙ МУСУЛЬМАНСКИЙ МИР**
МЕЖДУНАРОДНЫЙ НАУЧНЫЙ ЖУРНАЛ
РОССИЙСКОГО ИСЛАМСКОГО ИНСТИТУТА
www.islamjournal.ru

Юсупова Н. М. Урта гасыр төрки-татар шигъриятендә суфичылык традицияләре [Электронный ресурс] / Н. М. Юсупова, А. Ф. Юсупов // Современный мусульманский мир : электрон. журнал. – 2018. – № 1. – 1 электрон. опт. диск (CD-ROM). Систем. требования: Pentium III, процессор с тактовой частотой 800 Мгц; 128 Мб; 10 Мб; Windows XP/Vista/7/8/10; Acrobat 6 x.

**Современный мусульманский мир. 2018. №1. ID 29**
**ISSN: 2587-6848**
**Свидетельство о регистрации СМИ: ЭЛ № ФС 77 - 69532 от 25.04.2017**

шагыйре, мәдәният һәм дин эшлеклесе, дипломат Колшәриф иҗаты суфичылык рухында.

*Һу-һу тию һу кошы, акар күзендин яше,*
*Көеб эче һәм тышы, гафил торма, «Һу» тигел.*
*Гашыйклары очарлар, гарше шахига кунарлар,*
*Һу диеп, дидар кылырлар, гафил торма, «Һу» тигел.*

Шигырьструктур яктан шартлы төстә ике өлешне берләштерә: битарафлыкны җиңәргә, күзләрне ачарга, гыйлем алырга кирәклекхакындаукучыга мөрәҗәгать һәм зикернең мөһимлеге турында фәлсәфи фикер белдерү. Шагыйрь традицион суфи символларына мөрәҗәгать итә: бәхер (зөбәрҗәт) һәм гаувас (су астына чумучы) шундый образлар буларак аерылып чыга. Су астына чумучы гаувастирән серләргә төшенергә, илаһи гыйлемгә ирешергә омтылган кешене символлаштыра.Гарше шахи (күкнең тугызынчы каты) һәм гашыйк образлары ярдәмендә хакыйкатькә ирешү сурәте тудырыла һәм һәр строфада “белми торма” мөрәҗәгате кабатлана. Ул зикерне аңларга теләгән суфины “һу кошы” дип атый, һу зикере мистик юлны дәвам итүнең иң кулай ысулы буларак тасвирлана.

«Әлхәмдүлиллаһ раббил-галәми...» шигыре кешенең тәүбәгә килү баскычын сурәтләү объекты итеп күтәрә. Тәүбә– барлык гөнаһлардан арыну, бөтен дөнья кайгы-хәсрәтләреннән ваз кичү.

Шигырь Аллаһка мөрәҗәгать белән башлана. Лирик герой иманлы булуы, күңел тынычлыгы, бөек Коръәне-Кәрим һәм мөселман булып дөньяга килүе, Мөхәммәд пәйгамбәр, аның гамәлләре, Кыямәт көне хакындагы аңлатулары өчен Аллаһка рәхмәтен җиткерә. Шагыйрь догаларында берничә теләк аерылып чыга һәм автор фикерен төгәлләштерә: безнең нәфесебезне үзебезгә дошман итмә, гөнаһларыбызны ярлыка, кирәк булса, Үзең яныңнан куып җибәр, кирәк булса, Үзең безне каршы ал; өмет безне беркайчан да ташламасын. Моннан тыш, шигырьдә кайбер аятьләр урын ала һәм суфи шагыйрьнең нәкъ аларны искә төшерүе һәм укуы кебек кабул ителә. Охшаш мотивлар белән Хаҗи Бикташ фикерләрендә дә очрашабыз: ул да нәфес һәм алдауның кешегә явызлык булып әйләнеп кайтуын ассызыклый.

Шул рәвешле шигырь тәүбә мәкамендә Аллах белән диалог рәвешен ала. Бу мәкамдә булган суфиның ничек гыйбадәт кылырга, намазны ничек укырга тиешлеге бөртекләп тасвирлана. Бу тукталышның ничек үтелергә тиешлеге турында үзенчәлекле күрсәтмәләр урын ала. Автор Аллаһ белән сөйләшә; аның

СОВРЕМЕННЫЙ МУСУЛЬМАНСКИЙ МИР
МЕЖДУНАРОДНЫЙ НАУЧНЫЙ ЖУРНАЛ РОССИЙСКОГО ИСЛАМСКОГО ИНСТИТУТА
www.islamjournal.ru

Юсупова Н. М. Урта гасыр төрки-татар шигъриятендә суфичылык традицияләре [Электронный ресурс] / Н. М. Юсупова, А. Ф. Юсупов // Современный мусульманский мир : электрон. журнал. – 2018. – № 1. – 1 электрон. опт. диск (CD-ROM). Систем. требования: Pentium III, процессор с тактовой частотой 800 Мгц; 128 Мб; 10 Мб; Windows XP/Vista/7/8/10; Acrobat 6 x.

**Современный мусульманский мир. 2018. №1. ID 29**
**ISSN: 2587-6848**
**Свидетельство о регистрации СМИ: ЭЛ № ФС 77 - 69532 от 25.04.2017**

юлында булуын исбат итә; аерым намаз-догалар укый; үзе һәм башкалар исеменнән ярлыкавын сорап мөрәҗәгать итә.

Колшәрифнең “И күңел...” шигыре дә диалог рәвешендә язылган: лирик “мин” үз-үзенә, үз җанына эндәшә, тынычлык сорый, дөнья рәхәтенә, дөнья эшләренә карата игътибарсыз булырга тели. Шагыйрь зөхд баскычында тора [1: 208]. Билгеле булганча, бу мәкамдә кеше дөньядан читләшкән, хәләл һәм харамга карата битараф. Бу шигырьдә үлемсезлеккә омтылыш дөньяви бер мавыктыргыч кебек, йөрәкне Аллаһтан читләштерә торган күренеш буларак бәяләнә:

*Бу үлү ширбәтим халыкга ичүргән дөньядыр,*
*Сән сагынма дөньяда мән бакый кагаймән тийү.*

Охшаш үзенчәлекләр Мөхәммәдъяр иҗатында да урын ала. Мәсәлән, шагыйрьнең “Нәсыйхәт” шигырендә фәлсәфи фикерләр гөл-былбылпарлы суфи символлары аша яктыртыла, шуңа өстәп традицион баг, бакча (дөнья тормышының символы) һәм тикән (гомумән, начарлыкның яки начар кеше сыйфатларының символы булып тора) символлары кулланыла. Шулар аша чагылган идея дөньяда начарлыкның, имансызлыкның күп булуын искәртә һәм кайгы-хәсрәтләрнекешенең, ягъни бу бакча хуҗасының, имансызлыгына бәйләп аңлата.Автор дөньяның Аллаһны ярату принцибына нигезләнергә тиешлеген ассызыклап бара. Икенче катлам кешегә юнәлгән үгет-нәсыйхәттән формалаша: начар булма, ярат (“Гөле сач ул багыңа, булма җаһил); дөрес юлда бул һәм дөрес яшә.

Суфичылык традицияләре XVII гасырдаМәүла Колый иҗатында дәвам иттерелә. Шагыйрь алдагы традицияләрне дәвам итә, үстерә, шунын белән янәшәдә аның шигырьләрендә үзгә дөнья сурәтенең алга чыгуы да күзәтелә. Мәсәлән, Мәүла Колый иҗатында заһир – батыйн («Ачык» –«Яшерен») гарәп фәлсәфәсе категорияләре мистицизм терминнары рәвешендә килеп, яңа бер оппозицияне формалаштыралар. Аллаһка гашыйк дәрвиш өчен «Ачык» белән «Яшерен» арасындагы киртәне үтә алу мөһим санала, суфи шагыйрь галәмнең, илаһи көчнең батыйн ягын күрергә, аңа якынаерга омтыла:

*Тәүфикъ эстәп, тәүбә кылып яшьләр сачсам,*
*Нәфсе илә шәйтан ләгыйнь буйнын печсәм,*
*Хак әмренә бу күңелнең күзен ачсам,*
*Батыйн сүзләр заһир улып, гаян улыр.*

“Гыйлемлек хак рәхәтдер...” шигыре дә шушы ук мотивларга корылган. Шагыйрь, Хаҗи Бикташ кебек үк, бер-беренә ярдәм итәргә чакыра (“Карендәш

Юсупова Н. М. Урта гасыр төрки-татар шигърыятендә суфичылык традицияләре [Электронный ресурс] / Н. М. Юсупова, А. Ф. Юсупов // Современный мусульманский мир : электрон. журнал. – 2018. – № 1. – 1 электрон. опт. диск (CD-ROM). Систем. требования: Pentium III, процессор с тактовой частотой 800 Мгц; 128 Мб; 10 Мб; Windows XP/Vista/7/8/10; Acrobat 6 x.

**Современный мусульманский мир. 2018. №1. ID 29**
**ISSN: 2587-6848**
**Свидетельство о регистрации СМИ: ЭЛ № ФС 77 - 69532 от 25.04.2017**

мәхәббәте бал- шәкәрдин…”), сабырлык аша Аллаһка якынаерга өнди (“Морадына тиз йиткүси сабыр кеше”). Кешенең теге яки бу сыйфатларын атап, Мәүла Колый укучысы каршына суфи образын китереп бастыра, ул үз чиратында камил кеше булып күзаллана.

Уртагасыр татар шигърыятенә күз ташласак та, камил инсан концепциясененурын алуын күрәбез. Ләкин суфичылыкның бәхәсле һәм катгый тәгълиматы булган вөҗүдия фәлсәфәсендәге ачыктан-ачык пантеизм, яшәешне Аллага тәңгәлләштерү –камил инсанны онтологик яссылыкта шәрехләү –татар мәдәниятендә һәм әдәбиятында көчле түгел. Безнең җирлектә вәхдәт әш-шөһүд –«галәмдәге бар нәрсә дә Алладан» дип белдерүче классик теология киң тарала [11: 601]. Кеше һәрвакыт илаһи камиллеккә омтылырга тиеш дигән фикер әхлакый эчтәлек ала, камил инсан әхлакый һәм илаһи югарылыкка ирешкән идеал кебек кабул ителә.

Шул рәвешле, урта гасыртатар суфичылык поэзиясендә суфичыл символлар, фәлсәфи мотив һәм дөнья моделе еш күзәтелә, мондый әсәрләрдә үзенчәлекле терминологияурын ала [10: 275–284]. Дөнья сурәте дини-суфичылэчтәлектә бирелә, суфи әдәбиятка хасоппозицион вариантлар кулланыла. Күренәнчә, татар суфичылык шигърыятендә нәкшбәндия тәрикатенә хас фикер, фәлсәфә һәм дөнья моделе алга чыга.

Дини-суфичыл дөнья сурәте аеручатөрки-татар поэзиясенең күренекле әдипләре Кол Шәриф, Мөхәммәдъяр, Мәүла Колый иҗатларында алга чыга, бу авторлар суфичылык традицияләрен милли җирлектә үстерә-дәвам итә. Шәрык суфишагыйрьләриҗатында урын алган кеше / Алла, аның төрле вариантлары буларак шәхси / илаһи; җир тормышы / күк тормышы; ялган / хакыйкать, фани / бакый, матди / рухи һ.б. бинар оппозицияләре алар тарафыннан да актив кулланыла. Шуның белән янәшәдә татар поэзиясендә суфичылык символларының үзгә аңлатылыш вариантлары булуы [9: 75], камил инсан концепциясенең дә үзенчәлекле аңлатылышы күзәтелә. Ул үзенең нигез суфи тамырларыннан шактый ераклаштырылган һәм җирле күзаллауга, классик дини тәгълиматка яраклаштырылган сыйфатта чагылыш таба. Бу урта гасыр төрки-татар суфичылык шигърыятенең үзгәлеген тәшкил итә.

**СОВРЕМЕННЫЙ МУСУЛЬМАНСКИЙ МИР**
МЕЖДУНАРОДНЫЙ НАУЧНЫЙ ЖУРНАЛ
РОССИЙСКОГО ИСЛАМСКОГО ИНСТИТУТА
www.islamjournal.ru

Юсупова Н. М. Урта гасыр төрки-татар шигърияте ндә суфичылык традицияләре [Электронный ресурс] / Н. М. Юсупова, А. Ф. Юсупов // Современный мусульманский мир : электрон. журнал. – 2018. – № 1. – 1 электрон. опт. диск (CD-ROM). Систем. требования: Pentium III, процессор с тактовой частотой 800 Мгц; 128 Мб; 10 Мб; Windows XP/Vista/7/8/10; Acrobat 6 x.

**Современный мусульманский мир. 2018. №1. ID 29**
**ISSN: 2587-6848**
**Свидетельство о регистрации СМИ: ЭЛ № ФС 77 - 69532 от 25.04.2017**

*Кулланылган әдәбият исемлеге*

1. Заһидуллина Д. Ф. Картина мира и художественные особенности средневековой татарской суфийской поэзии // Ученые записки Казанского государственного университета. Книга 2. Т. 149. Серия гуманитарных наук. 2007. С. 206–216.

2. Ибрагим Т. Татарская религиозно-философская мысль в общемусульманском контексте. Казань, 2002. 239 с.

3. Игнатенко А. Мир – Бог в Зеркале, или как возник Совершенный Человек // Человек и Природа в духовной культуре Востока. М. : ИВ РАН : КРАФТ, 2004. С.14–47.

4. Йосыпова Н. М. XX гасыр татар шигъриятендә символлар. Казан : Казан университеты нәшр., 2011. 120 б.

5. Сибгатуллина Ә. Т. Татар әдәбиятында суфичылык (чыганаклар, тематика һәм жанр үзенчәлекләре) : филол.фн.докт...дисс. Алабуга, 2000. 335 б.

6. Степанянц М. Т. Философские аспекты суфизма. М. : Наука, 1987. 190 с.

7. Юсупова Н. М., Юсупов А. Ф.Суфийская символика в татарской поэзии XIX века // Филология и культура. 2014. № 36. С. 230–235.

8. Юсупова Н. М., Юсупов А. Ф.Символизация в тюрко-татарской поэзии средневековья и нового времени (на примере суфийских поэтических произведений) // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2015. № 10 (52). Ч.2. С. 209–211

9. Zagidullina D. F., Yusupova N. M., Yusupov A. F., Pair Sufi symbols in Tatar poetry of the 20th century: Complexity and transformation of symbols // XLinguae. 2017. V.10, Is.3. P. 75–82.

10. Yusupov A. F. Specifics of Sufi and Islamic terminology use in the poetry of the XIXth century // European Journal of Science and Theology. 2015. V.11. № .5. P. 275–284.

11. Yusupova N. M., Yusupov A. F. Tatar SUFI poetry of the XVI–XIX centuries: peculiarities, world models and symbolics // Life Science Journal. 2014. №. 11(11). P. 598–601.

**СОВРЕМЕННЫЙ МУСУЛЬМАНСКИЙ МИР**
МЕЖДУНАРОДНЫЙ НАУЧНЫЙ ЖУРНАЛ РОССИЙСКОГО ИСЛАМСКОГО ИНСТИТУТА
www.islamjournal.ru

Юсупова Н. М. Урта гасыр төрки-татар шигъриятендә суфичылык традицияләре [Электронный ресурс] / Н. М. Юсупова, А. Ф. Юсупов // Современный мусульманский мир : электрон. журнал. – 2018. – № 1. – 1 электрон. опт. диск (CD-ROM). Систем. требования: Pentium III, процессор с тактовой частотой 800 Мгц; 128 Мб; 10 Мб; Windows XP/Vista/7/8/10; Acrobat 6 x.

**Современный мусульманский мир. 2018. №1. ID 29**
**ISSN: 2587-6848**
**Свидетельство о регистрации СМИ: ЭЛ № ФС 77 - 69532 от 25.04.2017**

**Yusupova Nurfiya**
*Doctor of Philology, Associate Professor, Department of Tatar Literature, Kazan Federal University, Kazan.*
*faikovich@mail.ru*

**Yusupov Ayrat**
*Doctor of Philology, Associate Professor, Department of Tatar Linguistics, Kazan Federal University, Kazan.*
*faikovich@mail.ru*

# SUFIAN TRADITIONS IN THE MEDIEVAL TURK-TATAR POETRY

*In this article, Sufi traditions are revealed in the Turkic-Tatar poetry of the Middle Ages, the main development tendencies are revealed. On the material of Sufi poetic works are often used binary oppositions in the religious picture of the world, determine the semantic and philosophical and aesthetic load of Sufi symbols, their functions, role and artistic significance. Türko-Tatar poetry of this period is studied against the background of the reconstruction of the religious picture of the world, as well as in the broad context of Eastern literature and Islamic philosophy.*

*Key words: Sufism, tradition, symbol, world view, Turkic-Tatar poetry.*

**© АНО СНОЛД «Партнёр», 2018**
**© Юсупова Н. М., 2018**
**© Юсупов А. Ф., 2018**

**Учредитель и издатель журнала:**
Автономная некоммерческая организация содействие научно-образовательной и литературной деятельности «Партнёр»

ОГРН 1161300050130 ИНН/КПП 1328012707/132801001

**Адрес редакции:**
430027, Республика Мордовия, г. Саранск, ул. Ульянова, д.22 Д, пом.1
тел./факс: (8342) 32-47-56; тел. общ.: +79271931888;
E-mail: redactor@anopartner.ru

www.anopartner.ru
"ПАРТНЁР" ИЗДАТЕЛЬСТВО

**СОВРЕМЕННЫЙ МУСУЛЬМАНСКИЙ МИР**
МЕЖДУНАРОДНЫЙ НАУЧНЫЙ ЖУРНАЛ
РОССИЙСКОГО ИСЛАМСКОГО ИНСТИТУТА
www.islamjournal.ru

Юсупова Н. М. Урта гасыр төрки-татар шигъриятендә суфичылык традицияләре [Электронный ресурс] / Н. М. Юсупова, А. Ф. Юсупов // Современный мусульманский мир : электрон. журнал. – 2018. – № 1. – 1 электрон. опт. диск (CD-ROM). Систем. требования: Pentium III, процессор с тактовой частотой 800 Мгц; 128 Мб; 10 Мб; Windows XP/Vista/7/8/10; Acrobat 6 x.

**Современный мусульманский мир. 2018. №1. ID 29**
**ISSN: 2587-6848**
**Свидетельство о регистрации СМИ: ЭЛ № ФС 77 - 69532 от 25.04.2017**

**О журнале**

- ✓ Журнал имеет государственную регистрацию СМИ и ему присвоен международный стандартный серийный номер ISSN.
- ✓ Журнал является официальным изданием. Ссылки на него учитываются так же, как и на печатный труд.
- ✓ Редакция осуществляет рецензирование всех поступающих материалов, соответствующих тематике издания, с целью их экспертной оценки.
- ✓ Журнал выходит на компакт-дисках. Обязательный экземпляр каждого выпуска проходит регистрацию в Научно-техническом центре «Информрегистр».
- ✓ Журнал находится в свободном доступе в сети Интернет по адресу: **www.islamjournal.ru**. Пользователи могут бесплатно читать, загружать, копировать, распространять, использовать в образовательном процессе все статьи.

**Прием заявок на публикацию статей и текстов статей, оплата статей осуществляется через функционал Личного кабинета сайта издательства "Партнёр" (www.anopartner.ru) и не требует посещения офиса.**